КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 гыйнвар г.Казань № 17

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен раслау турында

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләренә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына күченү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү бирүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 гыйнвар, 17 нче
карары белән расланды

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм
Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән
Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен
бер тапкыр бирелә торган түләү бирү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) бирү механизмын билгели.

1.2. Бер тапкыр бирелә торган түләү Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 октябрендәге б-3099 номерлы боерыгы белән расланган исемлек буенча Херсон өлкәсенең торак пунктларында) даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән, даими яшәү урыны өчен Татарстан Республикасы территориясенә килгән һәм бер тапкыр бирелә торган түләү бирүгә гариза тапшырган гражданнарга (алга таба – гражданнар) бирелә.

1.3. Бер тапкыр бирелә торган түләү «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенең (алга таба – Фонд) финанс ярдәме исәбеннән бирелә.

1.4. Бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр бирелә.

1.5. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләме бер кешегә 100 000 сум тәшкил итә.

## II. Бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү тәртибе

2.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирү максатларында граждан, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итәргә вәкаләт бирелгән законлы вәкил яки зат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яшәү (тору яки фактта яшәү) урыны буенча территориаль социаль яклау органына (алга таба шул ук эзлеклелектә – Министрлык, территориаль орган) яисә Министрлык һәм «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе арасында үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешү нигезендә территориаль орган белән хезмәттәшлек итә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенә түбәндәгеләрне тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча язылган, гражданның кредит оешмасында ачылган шәхси счеты реквизитлары турында белешмә күрсәтелгән, бер тапкыр бирелә торган түләү бирү турында гариза (алга таба – гариза);

гражданның, аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (Россия Федерациясе гражданы паспорты яки шәхесне таныклый торган, шул исәптән Херсон өлкәсенең ачык хакимият органнары, Украина дәүләт хакимияте органнары, Украина җирле үзидарә органнары биргән һәм (яки) граждан хәлен раслый торган, Украина нотариуслары тарафыннан таныкланган башка документлар). Шул ук вакытта гражданның гаилә әгъзаларына ире (хатыны), балигъ булмаган балалары, 18 яше тулганга кадәр инвалид булган 18 яшьтән зуррак балалары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәр балалары, шулай ук ата-аналары һәм гражданның (иренең, хатынының) карамагында булган һәм алар белән бергә яши торган башка затлар кертеп карала;

гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган документ (яшәү урыны буенча теркәлү турында билгесе булган Россия Федерациясе гражданы паспорты, башка документлар яисә Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә күчемсез мөлкәткә милек хокукын раслый торган документ, әгәр мондый гражданның әлеге территорияләрдә даими яшәү фактын таныклый торган документы булмаган булса, гражданның Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган аңлатмасы теркәлә). Шул ук вакытта Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган документлары булмаган балигъ булмаган балаларның яшәү урыны итеп аларның ата-аналары, уллыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) һәм башка законлы вәкилләренең яшәү урыны танылa.

2.2. Документлар вәкил тарафыннан бирелгән очракта, гаризага Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә теркәлә һәм вәкилнең шәхесен таныклый торган документ күрсәтелә.

2.3. Бу Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар, төп нөсхәләрен күрсәтеп, күчермәләр рәвешендә яисә нотариаль таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Документларның күчермәләре (документларның нотариаль таныкланган күчермәләреннән тыш), төп нөсхәләре белән чагыштырып тикшерелгәннән соң, документлар кабул итүче зат тарафыннан раслана.

Украина телендә төзелгән документлар гади язма формада рәсмиләштерелә торган рус теленә тәрҗемә белән бирелә.

2.4. Гражданның 2022 елның 13 октябренә кадәр Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәвен раслый торган документлары булмаган очракта, территориаль орган гариза һәм документлар кергән көннән ике эш көне эчендә гражданның Херсон шәһәре яки Херсон өлкәсе территориясендә яшәвен раслау максаты белән Херсон өлкәсенең вәкаләтле органына рәсми сорау җибәрә.

2.5. Гаризаларны эшкәртү Фонд тарафыннан, «Торак-коммуналь хуҗалык реформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.6. Территориаль орган гариза һәм документлар кергән көннән биш эш көне эчендә, ә бу Тәртипнең 2.4 пунктында каралган очракта, гариза кергән көннән 15 эш көне эчендә бер тапкыр бирелә торган түләү бирү (аны бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

2.7. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

гражданның бу Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

бу Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның (белешмәнең) тапшырылмавы;

тапшырылган документларның яки гаризалардагы белешмәнең дөрес булмавы;

бер тапкыр бирелә торган түләүнең Россия Федерациясе башка субъектында алынуы.

2.8. Территориаль орган бер тапкыр бирелә торган түләү бирү турында йә бер тапкыр бирелә торган түләүне бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә гражданга яки аның вәкиленә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хәбәрнамәдә баш тартуның нигезләре күрсәтелә.

2.9. Бер тапкыр бирелә торган түләүне күчерү Министрлык тарафыннан Фонд Татарстан Республикасы бюджетына акчаны күчергән көннән 10 эш көне эчендә гражданнарның кредит оешмаларында үзләре ачкан шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган түләүне күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.10. Граждан тарафыннан законсыз рәвештә, шул исәптән дөрес булмаган белешмә белән документлар тапшыру, аны билгеләү хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү аркасында алынган бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы граждан тарафыннан законнар белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

______________________________